**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 апрель № 238

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләрен раслау хакында» 2011 ел, 9 август, 643 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләрен раслау хакында» 2011 ел, 9 август, 643 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 124 нче, 2015 ел, 24 октябрь, 800 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның

15еннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Федераль инвестицион программаларны тормышка ашыру буенча берләшкән дирекция» федераль казна учреждениесенә эчтәлеккә, формасына һәм бирү тәртибенә карата законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында хисап бирергә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 8 декабрь, ФЗ-342 нче Федераль закон нигезендә торак урыннар белән тәэмин ителүче гражданнарга милеккә түләүсез яки социаль найм буенча торак урыннар бирү, аларга торак урын сатып алу йә төзү өчен бер тапкыр акчалата түләү бирү кагыйдәләрендә:

2 пунктның беренче абзацында:

«2005 елның 1 гыйнварына кадәр» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә» сүзләрен өстәргә;

8 пунктта:

«15 статьяның 8 пункты» сүзләрен «15.1 статьяның 2 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның җиденче абзацында:

«15 статьяның 8 пункты» сүзләрен «15.1 статьяның 2 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның җиденче абзацында:

«15 статьяның 8 пункты» сүзләрен «15.1 статьяның 2 пункты» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков